КАРАР

21 ноябрь 2023 ел №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авылы җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 20ноябрендә, 2023 елның 21 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авылы, Түбән Өскебаш авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан, Хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2024 елда үзара салым кертүгә 1000 сум күләмендә риза булырсызмы?

- вак таш җәю, Түбән Өскебаш авылында юлларны карап тоту һәм ремонтлау; проект-смета документларын төзү , технадзор;

- Түбән Өскебаш авылында юлларны кыш көне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Түбән Өскебашта урнашкан артезиан скважиналарына насослар сатып алу;

-Су башняларына койма тоту( материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- су башняларын, су белән тәэмин итү системаларын, су саклау зоналарын ремонтлау, карап тоту, тозекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү

-янгын сүндерү машинасына запчастләр сатып алу; кую; янгын сүндерү машинасына ремонт ясау, ДЕПО бинасына ремонт ясау; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү

- Түбән Искубаш авылында су үткәрү, су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, су башнясын ремонтлау һәм урнаштыру; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган ,җыенда катнашучылар исемлегенә, 286 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 145.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 145 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны таныргa: «2024 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авылы, Түбән Өскебаш авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм

студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан, Хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- вак таш җәю, Түбән Өскебаш авылында юлларны карап тоту һәм ремонтлау; проект-смета документларын төзү , технадзор;

- Түбән Өскебаш авылында юлларны кыш көне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Түбән Өскебашта урнашкан артезиан скважиналарына насослар сатып алу;

-Су башняларына койма тоту( материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- су башняларын, су белән тәэмин итү системаларын, су саклау зоналарын ремонтлау, карап тоту, тозекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү

-янгын сүндерү машинасына запчастләр сатып алу; кую; янгын сүндерү машинасына ремонт ясау, ДЕПО бинасына ремонт ясау; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү

- Түбән Искубаш авылында су үткәрү, су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, су башнясын ремонтлау һәм урнаштыру; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирлеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов